БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» 08 2025 ел № 234

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә комплексլы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясенең эш регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2025 елның 18 февралендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясен төзү турында» 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясенең эш регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.5 пунктта «тәкъдим ителергә мөмкин» сүзләрен «тәкъдим ителә»сүзенә алмаштырырга.

1.2. 4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Килештерү комиссиясе утырышлары комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү турында мәгълүмат килгәндә уздырыла.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов